

*...Укып сине ишетэм хэбэрлэрне*
*Уныш телэп торам көчле халкыма.*
*Сезнен белэн мин дэ бергэ диеп,*
*Шатлыгымнан йөрэк талпына.*

Шулай безнен “Юлдаш» газетасын яратып 5 куплетлы шигырь (югарыда озек) яза Мәскәвдә яшәvче Шәяхмәт Мохәммәтша улы Жиганшин. Ул 1946нчы елда Горький олкәсе Кызыл Октябрь районы Шоба (Шубино) илендә туа.

Шоба мәктәбендә белем алганнан сон, Арзамас техникумында авыл хужалыгын механизацияләv һәм электрофикацияләv бvлеген тәмамлый, Советлар Армиясе сафында ракетчик булып хезмәт итә, батарея комсомол секретаре дә була. Аннары, 1969-2009нчы елларда Мәскәv автомобильләр жыю заводында (ОАО «Москвич». Автомобильный завод АЗЛК) слесарь-сборщик, инженер, баш механик, цех житәкчесе, генераль директорнын урынбасары булып хезмәт итә.Тырыш хезмәтенә кvпторле бvләкләре дәлил.. Шәяхмәт Мохәммәтша улы тормыш иптәше Зәкия Равиль кызы Салехметова (тумышы белән Торбеево районы Татар Йонәсе авылыннан) белән гаилә корып тату гомер итәләр. Зәкия Равиль кызы Мордовия педагогия институтын тәмамлап, гомере буе укытучылык итә; туган Татар Йонәсе авылы мәктәбендә дә, Мәскәvдә дә. Жиханшиннар ике кыз бала, Альфия белән Голсемне тәрбияләп vстерәләр; бvген - югары белемле белгечләр. Аларнын балалары - Роберт белән Алина, әби-бабайларын шатландырып vсәләр. Шәяхмәт Мохәмметша улы белән Зәкия Равиль кызынын балалары бvген Мәскәvдә пенсионер әти-әниләренә ярдәм итеп яшиләр. Унган кеше барлык яктан унган, диләр, бу чынлап та шулай. Шәяхмәт Мохәмметша улын алтын куллы дип тә әйтергә була: лаеклы ялга чыккач, vз проекты буенча, гаражлы, мунчалы дача сала. Бакчаларында нәрсә генә vстермиләр алар, керсән - сокланырлык! Барлык эш-гамәлләре белән бергә, кvнел очен, шигырьләр дә яза Ш. М.Жиганшин. 20дән артык шигырь язган инде. Шәяхмәт Мохәмметша улы Торбеево районы Татар Йонә авылына кунакка кайткач дуслашып китә дә инде Мордовия республикасында нәшер ителә торган «Юлдаш» газетасы белән. Хисләре кvнеленен ин тирән почмакларыннан ургылып шигъри юлларында чыга. «Укып сине ишетәм хәбәрләрне.Уныш теләп торам кочле халкыма.Сезнен белән мин дә бергә диеп, шатлыгымнан йорәк талпына»,- дип тә

куя «Юлдаш» газетасына багышлап язган шигырь юлларында. Кин кvнелле кеше ул. Татар Йонәсе кызын гына тvгел, Мордовияне, халкын да ярата Шәяхмәт әфәнде. Шул яраткан халкына ана телендә, булдыралган дәрәжәдә, шигырьләр яза. Якташ язучыбыз Хади Такташка да поэма багышлый. Аннан озек:

*...Карыйм шул син йөргэн урамнарга*
*Чыгарсын дип кинэт юлыма.*
*Исэнме син мишэр Шэяхмэт диеп,*
*Сузарсын диеп кулын кулыма.*
*Никтер сине кvргем кели*
*Тавышынны иштеп карап кvзенэ.*
*Мин дэ сина сэлам бирер идем*
*Кочып, ирегеп, сөеп, ярап vзенэ.*

**Н.Хәлил**